# КАРАР
## Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Салтык авыл җирлегенең Даныш авылында гражданнарга үзара салым кертү турында

04 декабрь 2023 ел № 3

“Россия Федерациясендә җирле узидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 121-ФЗ номерлы Федераль законнын 25,1, 56 статьялары, “Татарстан Рес публикасында җирле узидарә турында” 2004 елнын 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Даныш авылында гражданнар җыены **карар итте** :

1.Үзара салымны 2024 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Салтык авыл җирлегендә Даныш торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча укучы студентлар кала 1000,00 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәгеләрне үтәү буенча юнәлтергә:

- **торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту** (шул исәптән вак таш сатып алу, ташу һәм салу, су агымы торбаларын урнаштыру, юлларны кардан грейдировкалау һәм чистарту);
- **җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү** (шул исәптән төзелеш материаллары сатып алу);
- **торак пункт территориясен төзекләндерү** (шул исәптән җәйге вакытта территорияне кисү, трактор өчен запас частьләр сатып алу, ягулык-майлау материаллары сатып алу);
- **ремонт, коймалар төзү, традицион күмү урыннарын төзекләндерү** (шул исәптән зират территориясен чистарту һәм җыештыру).

3. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмати стендларда халыкка җиткерергә:
- ТР, Кама Тамагы районы, Олы Салтык авылы, Свердлов урамы, 126 йорт;
- ТР, Кама Тамагы районы, Даныш авылы, Кооператив урамы, 71, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә 10 (ун) көн эчендә урнаштырырга кирәк.

Халык җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы КамаТамагы
муниципаль районы Олы Салтык
авыл җирлеге башлыгы Р.М. Вафин